СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**28.12.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 259**

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый нигезләрен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 8 маендагы 83-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 26 июлендәге 202-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында» 2013 елның 6 маендагы 262 номерлы карарының 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Расланган

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2017 елның
28 декабрендәге 259 номерлы
карары белән

**«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Административ-техник инспекциясе идарәсе» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмә**

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба - Идарә) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә төзелде.

1.2. Идарәне гамәлгә куючы - «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы - Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы йөзендә Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге.

Оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт милекчесе - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты яисә ул вәкаләт биргән орган йөзендә Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге.

1.3. Идарә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Зеленодольск муниципаль районы Уставына, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.4. Идарә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының органы булып тора, юридик затларны теркәү турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве үткән вакыттан алып юридик зат статусына ия.

1.5. Идарәнең структурасы, штат расписаниесе, Зеленодольск муниципаль районының башкарма комитеты, Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы белән килештереп, Россия Федерациясе законнары һәм Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә Идарә башлыгы тарафыннан раслана.

1.6. Идарә табыш китерә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга мөмкин. Күрсәтелгән эшчәнлектән алынган керемнәр «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына керә.

1.7. Идарә мөстәкыйль баланс, бюджет сметасы һәм аңа билгеләнгән законлы тәртиптә ачылган шәхси счетка, салым түләүченең идентификация номерына, мөһергә, үз исеме язылган бланкларга ия булырга хокуклы.

1.8. Идарә үз исеменнән гражданлык әйләнешендә катнашырга, сатып алырга һәм билгеләнгән законнар, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Нигезләмә һәм оештыручысы кысаларында гражданлык һәм башка хокукларны һәм бурычларны үтәргә хокуклы.

1.9. Идарәнең тулы исеме: «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Административ-техник инспекциясе идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

Кыскартылган исеме: «Зеленодольск муниципаль районының административ-техник инспекциясе» МКУ.

1.10.Идарәнең урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре. Юридик адрес: 422540, Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Зеленодольск шәһәре, Норкин урамы, 3 нче йорт

## II. ИДАРӘ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ПРЕДМЕТЫ ҺӘМ МАКСАТЛАРЫ

2. Идарә эшчәнлегенең предметы һәм максаты - Зеленодольск муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында үз компетенциясе кысаларында контроль функцияләр үтәү, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү максатларында, төзекләндерү өлкәсендә тиешле вәкаләтләрне тапшыру һәм законда билгеләнгән тәртиптә Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында килешүләр нигезендә контроль функцияләрен үтәү, аерым алганда, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль норматив хокукый актларны үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, Зеленодольск муниципаль районы территориясен төзекләндерү дәрәҗәсен арттыру.

## III. ИДАРӘ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ ҺӘМ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

3.1. Закон нигезендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән килешүләр нигезендә Идарәгә түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

3.1.1. шәһәрне төзекләндерү өлкәсендә хокук бозуларны ачыклау һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итүдә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, башка оешмалар, шулай ук вазыйфаи затлар һәм гражданнар белән билгеләнгән тәртиптә үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

3.1.2. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан физик һәм юридик затларның, шәхси эшкуарларның төзекләндерү, инженерлык-коммуникация (җир) җитештерү, төзекләндерү объектларында ремонт һәм башка эшләр башкару, яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау өлкәсендә норматив хокукый актларны үтәү өлешендә эшчәнлеген контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

3.1.3. ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, аларны бетерү срокларын күрсәтеп, күрсәтмәләр бирергә һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерүне тикшереп тору чараларын, шулай ук ачыкланган хокук бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту чараларын күрү;

3.1.4. җирле әһәмияттәге махсус сакланылыла торган табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

3.1.5. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру;

3.1.6. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

3.1.7. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру.

3.2. Идарә түбәндәгеләргә хокуклы:

3.2.1. билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, хокук саклау органнары, дәүләт һәм ведомствоара комиссияләр һәм инспекцияләр, административ комиссия, башка оешмалар, шулай ук вазыйфаи затлар һәм гражданнар белән Идарә вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;

3.2.2. Идарәгә йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан соратып алырга;

3.2.3. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, физик һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләре буенча үз компетенциясе чикләрендә тикшерүләр уздырырга;

3.2.4. «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә ачыкланган бозуларны бетерү турында, бетерү срокларын күрсәтеп, күрсәтмәләр бирергә,ә аларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә язма рәвештә хәбәр итәргә;

3.2.5. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының статьяларындагы эшләрне караганда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Административ комиссиясе утырышларында катнашырга;

3.2.6. төзелеш объектларында муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешен, төзекләндерү, инженер-коммуникация (җир), төзекләндерү һәм башка эшләрне башкару, яшел үсентеләрне булдыру, карап тотуны һәм саклауны тикшерү максатларында, нинди милек булуы формаларына карамастан, контрольгә алынырга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларына барырга;

3.2.7. җир эшләре җитештерүне мониторинглау һәм бозылган төзекләндерү эшләрен торгызуны башкарырга;

3.2.8. ордерлар буенча җир эшләрен җитештерү, шул исәптән авария-торгызу эшләре башлану һәм тәмамлану срокларының үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

3.2.9. төзекләндерү өлкәсендә хокук бозуларны профилактикалау (шәһәрне санитар чистарту, гамәлдәге яшелләндерелгән территорияләрне яңача төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләре, яшелләндерелгән территорияләрне һәм тышкы төзекләндерүнең башка объектларын карап тоту);

3.2.10. автомобиль юлларының, яшел утыртмаларның һәм тышкы төзекләндерүнең башка объектларының сакланышын тәэмин итү буенча контрольне гамәлгә ашырырга;

3.2.11. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан коммуналь инфраструктура объектларының тиешенчә эксплуатацияләнүен төзекләндерү өлкәсендә муниципаль хокукый актларны үтәү өлешендә контрольне гамәлгә ашырырга;

3.2.12. Идарә компетенциясе өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында муниципаль ихтыяҗлар өчен, шулай ук үз ихтыяҗлары өчен товарлар кайтаруга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелә торган контрактлар буенча муниципаль заказчы сыйфатында катнашырга;

3.2.13. билгеләнгән тәртиптә Идарә эшендә катнашу өчен белгечләр һәм экспертлар җәлеп итәргә;

3.2.14. Идарә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарга кагылышлы өлешендә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты проектын формалаштыруда катнашырга; ;

3.2.15. Идарә компетенциясенә бәйле бәхәсләр буенча судларда катнашырга, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән;

3.2.16. Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләр территорияләрен төзекләндерү өлкәсендә муниципаль программаларны, башка норматив хокукый актларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашырга;

3.2.17. төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль нәтиҗәлелегенә мониторинг ясауны һәм уздыруны;

3.2.18. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен үтәлешен, тәртип һәм чисталык белән тәэмин итүне, җәмәгать транспорты тукталышларын һәм тукталыш павильоннарын карап тотуны контрольгә алырга;

3.2.19. шәһәрнең муниципаль милкендәге урман кишәрлекләренә карата муниципаль урман контролен гамәлгә ашырырга;

3.2.20. хокук бозу очраклары ачыкланган очракта, аларны карау Идарә компетенциясенә кермәгәндә, мәгълүматны, материалларны башка контрольлек органнарына җибәрергә;

3.2.21. гражданнарны кабул итүне гамәлгә ашырырга, гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм тулысынча карауны тәэмин итәргә, алар буенча карарлар кабул итәргә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта җаваплар җибәрергә;

3.2.22. әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә законнарда һәм муниципаль хокукый актларда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга.

3.3. Идарә үз вәкаләтләрен муниципаль контроль буенча нигезләмәләр һәм административ регламентлар нигезендә гамәлгә ашыра.

## IV. ИДАРӘ ЭШЧӘНЛЕГЕ БЕЛӘН ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ ҺӘМ ОЕШТЫРУ

4.1. Идарә эшчәнлеге белән законнар һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән чикләрдә бер генә кеше башкара торган принципта Идарә башлыгы җитәкчелек итә

4.2. Идарә башлыгы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә закон нигезендә төзелә торган контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе итеп билгеләнә.

4.3. Идарә башлыгы Идарә эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча түбәндәге функцияләрне башкара:

4.3.1. Идарә тарафыннан булдырылган максатларның үтәлешен тәэмин итә;

4.3.2. Идарә исеменнән ышанычнамәсез эш итә, аның мәнфәгатьләрен хакимият органнарында, предприятиеләрдә, оешмаларда, учреждениеләрдә яклый;

4.3.3. законнарда, әлеге Нигезләмәдә, башка муниципаль хокукый актларда, контрактта һәм мөлкәтне беркетү турындагы шартнамәдә билгеләнгән чикләрендә Идарә исеменнән шартнамәләр төзи, ышанычнамәләр тапшыра, башка гамәлләр кыла;

4.3.4. билгеләнгән ассигнованиеләр чикләрендә Идарәнең штат расписаниесен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә раслау өчен кертә;

4.3.5. үз компетенциясе чикләрендә Идарәнең барлык хезмәткәрләре һәм башка затлар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш булган боерыкларны чыгара;

4.3.6. билгеләнгән тәртиптә эш бирүченең барлык вәкаләтләрен Идарә хезмәткәрләренә карата, шул исәптән Идарә хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп куя һәм аннан азат итә, аларга законнар нигезендә дисциплинар җәза һәм бүләкләү чараларын куллана;

4.3.7. хисапларны, шул исәптән тиешле органнарга билгеләнгән форма буенча бухгалтерлык һәм статистик хисапларны тапшыруның вакытында һәм тулылыгын исәпкә алу торышы өчен җавап бирә;

4.3.8. әлеге Нигезләмәдән килеп чыга торган һәм гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка функцияләрне башкара.

## V. МИЛЕК ҺӘМ ФИНАНСЛАР ИДАРӘСЕ

5.1. Идарә аңа бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән мөлкәт һәм акча, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бурычларны тормышка ашыру өчен куллана.

5.2. Идарә мөлкәте аңа милек белән оператив идарә итү хокукында беркетелә.

5.3. Аңа беркетелгән милеккә карата Идарә гамәлдәге законнарда, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чикләрдә һәм үз эшчәнлеге максатларына ярашлы рәвештә милек, файдалану хокукын гамәлгә ашыра.

5.4. Идарә үз карамагындагы акча чаралары белән үзенең йөкләмәләре буенча җавап бирә. Алар җитмәгәндә, аның йөкләмәләре буенча субсидия җаваплылыгына тиешле мөлкәт милекчесе - Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җаваплылык тота.

5.5. Идарә үзенә бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән сатып алынган мөлкәт хисабына үзләренә беркетелгән мөлкәтне кире кагарга яисә башка ысул белән эш итәргә хокуксыз.

5.6. Идарәнең мөлкәте һәм чаралары аның балансында чагыла һәм гамәлдәге законнар нигезендә файдаланыла.

5.7. Милекче артык, файдаланылмый торган яисә тиешенчә файдаланылмый торган мөлкәтне алырга һәм алар белән үз теләгә буенча эш итәргә хокуклы.

5.8. Мөлкәт һәм идарә итү чаралары чыганагы булып, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты акчасы тора

5.9. Идарәнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге расланган бюджет чыгымнарның сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VI. ҖАВАПЛЫЛЫК

6.1. Идарә башлыгы түбәндәгеләр өчен җаваплы:

6.1.1. Идарәгә йөкләнгән төп бурычларны, вазыйфаларны һәм үз бурычларын үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү өчен;

6.1.2. конфиденциаль һәм хезмәт мәгълүматын фаш иткән өчен;

6.1.3. башкару һәм хезмәт дисциплинасын үтәмәгән өчен;

6.1.4. Идарәнең эш нәтиҗәләре өчен.

6.2. Идарә хезмәткәрләренең җаваплылыгы идарә хезмәткәрләренең җаваплылыгын билгеләүче вазыйфаи инструкцияләр һәм башка норматив хокукый документлар белән билгеләнә.

## VII. ИДАРӘНЕ БЕТЕРҮ ҺӘМ ҮЗГӘРТЕП КОРУ ТӘРТИБЕ

7.1. Идарәне үзгәртеп кору һәм бетерү Россия Федерациясе Гражданлык кодексында каралган тәртиптә һәм формаларда башкарыла.

7.2. Идарәне үзгәртеп кору турында карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы кабул итә.

7.3. Идарәне үзгәртеп корганда аның барлык документлары хокукый дәвамчыга тапшырыла. Документлар тапшыру гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

7.4. Идарәне бетерү Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән гамәлгә ашырыла.

7.5. Идарәне бетерү гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган Ликвидация комиссиясе тарафыннан башкарыла.

7.6. Ликвидация комиссиясе ликвидация балансын төзи.

7.7. Зеленодольск муниципаль районы Советы (гамәлгә куючы) гамәлдәге законнар нигезендә Идарәне бетерү тәртибен һәм срокларын билгели, дип раслый ликвидация балансы.

7.8. Ликвидация комиссиясе билгеләнгәннән соң, аңа ябылган Идарәнең эшләре белән идарә итү вәкаләтләре күчә.

7.9. Идарә ябылганда кредиторларның таләпләре Россия Федерациясе гражданлык законнарында билгеләнгән чират тәртибендә канәгатьләндерелә.

7.10.Идарәнең кредиторлар таләпләрен канәгатьләндергәннән соң, калган мөлкәте, юкка чыгарылган очракта, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкенә тапшырыла.

7.11.Ликвидация комиссиясе Идарәгә китерелгән зыян өчен законнар нигезендә җавап тота.

7.12.Идарәне бетерү тәмамланган дип, ә Идарә, бу хакта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгәннән соң, үз эшен туктаткан дип санала.

## VII. ӘЛЕГЕ НИГЕЗЛӘМӘГӘ ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТӘРТИБЕ

8.1. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән гамәлгә ашырыла.

8.2. Әлеге Нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве датасыннан үз көченә керә.